# КАРАР
## Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодур авыл җирлеге Советы

Чемодур авылы №148 «5» ноябрь 2019 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодур авыл җирлеге Советының «Физик затларның милкенә салым турында» 24.11.2014 ел №116 карарына (15.08.2015 елның 139 номерлы, 07.04.2018 елның 92 номерлы, 13.11.2018 елның 115 номерлы, 21.12.2018 елның 119 номерлы, 25.06.2019 елның 137 номерлы карарлар редакциясендә) үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында» 29.09.2019 елдагы 325-ФЗ номерлы Федераль закон нигезедә

Чемодур авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодур авыл җирлеге Советының «Физик затларның милкенә салым турында» 24.11.2014 ел №116 карарына (15.08.2015 елның 139 номерлы, 07.04.2018 елның 92 номерлы, 13.11.2018 елның 115 номерлы, 21.12.2018 елның 119 номерлы, 25.06.2019 елның 137 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 пунктның 1 пунктчасындагы өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«шәхси ярдәмче хуҗалык, яшелчәчелек, бакчачылык яки шәхси торак төзелеше алып бару өчен җир кишәрлекләрендә урнашкан һәм һәрберсенең мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган хуҗалык биналары яки корылмалары;».

1.2. 3.2 пунктында:

а) дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Салымнар һәм җыемнар турындагы законнарда билгеләнгән салым ташламаларына хокукы булган салым түләүчеләр үзләре сайлаган салым органына салым ташламаларын бирү турында гариза бирәләр, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документларны тапшырырга хокуклы. »;

б) җиденче абзацны түбәндәге эчтәлектәге җөмлә белән тулыландырырга:

«Сайлап алынган салым салу объектлары турында хәбәрнамә салым органына дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша тапшырылырга мөмкин».

3. Әлеге карар 2020 елның 01 гыйнварыннан, ләкин рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да ким булмаган вакыт үткәннән соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарны район «Маяк» газетасында бастырырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru. һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http//aznakayevo.tatar.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, салымнар, финанслар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Н.Б.Котельникова